| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2023 г. Казань № 112-2/э-2023

2023 елга «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте арасында челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

17.05.2023 ел, №А65-36159/2022 эш буенча Татарстан Республикасы Арбитраж суды карарын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 16.08.2023 ел, № 31-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2023 елга календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2023 елга кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын гамәлдән чыккан дип танырга:

« В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 3-2/э;

«В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-2/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 18.11.2020 № 232-6/э-2020;

«В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-2/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 03.12.2021 № 434-21/э-2021;

«В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-2/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 16.11.2022 № 524-16/э-2022.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.08.2023 № 112-2/э-2023
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2023 елга календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1. | «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте | 2023 | 52 211,44 | 25,99 | 0,20010 | 52 211,44 | 25,99 | 0,20010 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.08.2023 № 112-2/э-2023
карарына кушымта

2023 елга «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кирәкле тулай
кереме (югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы Татарстан Республикасында | Ел | Челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы (югалтуларны исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Татнефть – Энергосбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2023 | 562 530,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге